**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.02.2019** **№ 405**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «2015-2020 елларга Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш» муниципаль программасын раслау турында” 2014 ел, 20 нче октябрь 2004 нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү, муниципаль районда коррупция хокук бозуларын кисәтүгә ярдәм итүче чараларның нәтиҗәлелеген арттыру максатларыннан һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2015-2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру” дәүләт программасын раслау турында” 2014 ел, 19 июль, 512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2018 ел, 10 сентябрь, 763 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «2015-2020 елларга Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш» муниципаль программасын раслау турында” 2014 ел, 20 нче октябрь 2004 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә һәм 1 пунктта “2015-2020” саннарын “2015-2021” саннарына алыштырырга;

2) “2015-2020 елларга Биектау муниципаль районының коррупциягә каршы көрәш муниципаль программасы» кушымтасында:

а) “2015-2020” саннарын “2015-2021” саннарына алмаштырырга;

б) Программа паспортында:

- “Программаның исеме” юлындагы “2015-2020” саннарын “2015-2021” саннарына алыштырырга;

- “Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары” юлында “2015-2020” саннарын “2015-2021” саннарына алыштырырга;

- “Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары” юлында түбәндәге редакциядә бәян

итәргә: Җирле бюджет чаралары хисабына финанслауның гомуми күләмнәре 960 мең сум, шул исәптән 2015 елда – 120 мең сум; 2016 елда – 120 мең сум; 2017 елда - 130 мең сум; 2018 елда – 140 мең сум; 2019 елда – 140 мең сум; 2020 елда – 150 мең сум; 2021 елда – 160 мең сум.

3) “Кереш өлеш” бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Әлеге Программа Россия Федерациясе Президентының “2014 – 2015 елларга коррупциягә каршы торуның илкүләм планы турында” 2014 ел, 11 нче апрель, 226 нчы номерлы, “2016 – 2017 елларга коррупциягә каршы торуның илкүләм планы турында” 2016 ел, 1 нче апрель, 147 нче номерлы, “2018 – 2020 елларга коррупциягә каршы торуның илкүләм планы турында” 2018 ел, 29 нчы июнь, 378 нче номерлы Указларын, “Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында” 2006 ел, 4 нче май, 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2015-2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру” дәүләт программасын раслау турында” 2014 ел, 19 июль, 512 номерлы карарын (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.10.2015 № 741, 20.02.2016 №104, 26.05.2016 № 354, 09.11.2016 № 832, 26.05.2017 №311, 26.03.2018 № 174, 10.09.2018 №763лы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне дә истә тотып) үтәү йөзеннән эшләнгән.

4) Программаның IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

“IV Программаның ресурслар белән тәэмин итүен нигезләү”

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты чаралары хисабына гомуми финанслау күләме 860 мең сумны тәшкил итә, шул исәптән:”

| Ел | ТР Биектау муниципаль районы бюджеты чаралары (мең сум) |
|---|---|
| 2015 | 120,0 |
| 2016 | 120,0 |
| 2017 | 130,0 |
| 2018 | 140,0 |
| 2019 | 140,0 |
| 2020 | 150,0 |
| 2021 | 160,0 |
| Барлыгы | 860,0 |

Программаны финанслау күләме фаразлау характерында һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты чаралары мөмкинлекләрен истә тотып ел саен тәгаенләнә.

Моның өстенә программа чараларын тормышка ашыру өчен чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслау өчен бүлеп бирелә торган чараларны да куллану күздә тотыла.”;

5) Программаның V бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“V Программаны тормышка ашыру механизмы һәм аның үтәлешен контрольдә тоту”

“Программаны тормышка ашыру барышы һәм нәтиҗәлелеге турында еллык хисапны

(алга таба – еллык хисап) программаны башкаручылар хисап елыннан соң килүче елның  1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы буенча эшчәнлекне координацияләү буенча комиссия сәркатибенә мөрәҗәгать итү һәм алга таба Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башлыгына тәкъдим итү өчен тәкъдим итәләр. Еллык хисап Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иҗтимагый советы утырышында, гражданнар җыеннарында ел саен тыңланыла. Еллык хисап шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы тору  буенча эшне координацияләү комиссиясенең еллык эш планы нигезендә ел саен тыңланыла. Программа чараларын тормышка ашыру һәм үтәү буенча үсеп баручы нәтиҗәләр белән квартал саен хисапларны программаны башкаручылар хисап кварталыннан соң килүче 1 нче числога кадәр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясенең сәркатибенә гомумиләштерү өчен тәкъдим итәләр. Еллык һәм квартал саен хисаплар Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырыла.”;

6) VI бүлекнең Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге бүлекчәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка текст буенча 2021-100% дип өстәргә

2 пунктка текст буенча 2021-0,1% дип өстәргә

3 пунктка текст буенча 2021- 0 дип өстәргә

4 пунктка текст буенча 2021- 0 дип өстәргә

5 пунктка текст буенча 2021- 0 дип өстәргә

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/  веб-адресында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресында урнашытырып халыкка җиткерергә.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Биектау  муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе — Д.Ф.Шәйдуллин